ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**25.09.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1830**

Зеленодольск шәһәрендә торак урыны мәйданының исәп нормасын һәм торак урын бирү нормасын билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50 статьясына, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

1.1. Торак урыны мәйданының исәпкә алу нормасы, шуннан чыгып, гражданнарның торак урынының гомуми мәйданы белән тәэмин ителеше дәрәҗәсе, аларны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында, гаиләнең бер әгъзасына 18 кв. м күләмендә торак урынының гомуми мәйданы белән тәэмин итү дәрәҗәсе билгеләнә.

1.2. Социаль наем шартнамәсе буенча торак урынның гомуми мәйданын бирү нормалары:

- гаиләнең бер әгъзасына торак урынның гомуми мәйданы 18 кв.м. күләмендә, әмма ялгыз яшәүче граждан өчен гомуми мәйдан кимендә 33 кв.м. тәшкил итә;
- ике кешелек гаилә өчен торак урынның гомуми мәйданы 42 кв.м.

2. «Зеленодольск шәһәрендә торак урын мәйданының исәпкә алу нормасын һәм торак урынны бирү нормасын билгеләү турында» 2010 елның 19 мартындагы 01-08-83 нче карарын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигына массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга , Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы А.В. Старостин